# САРМАН ЕГЕТЕ
## Рафис Могыйнов
## иҗатына бер караш

Үзен күреп белгәнчегә кадәр, иң элек мин аның «Шәһри Чаллы» газетасында дөнья күргән язмалары аша таныштым бугай. Соңрак, язмыш үзе белән очраштырды. Бер-ике сөйләшеп аралашуга ук, аның кызыклы әңгәмәдәш, эзләнүчән, үз эшенең остасы, максатларына таләпчән кеше булуын аңладым.

Рафис Әмерсәяф улы Могыйнов 1948 елның 15нче апрелендә Татарстан Республикасының Сарман районы Мортышбаш авылында укытучылар гаиләсендә туган. 1966 елны Сарман урта мәктәбен тәмамлый. Район газетасында корректор, әдәби сотрудник булып эшли. 1967 елда армияг сафларына алына.Сарман егетен язмыш армия хезмәтенә Украинага китерә.

Бер елдан артык хезмәт иткәч, ул Львов шәһәрендәге югары хәрби-сәяси училищеның журналистика факультетынаукырга керә. Аны уңышлы гына тәмамлагач, армия хезмәтен Урта Азия хәрби округында дәвам итә. Сугышлар тарихын тирәнтен өйрәнгән Рафис, Украина, Белоруссия һәм Германия җирләрендә күп еллар яшәп, хәбәрсез югалганнарны яисә аяусыз сугыш кырларында мәңгегә башларын салган милләттәшләребезнең каберләрен эзләп табуда зур тырышлыклар куя. Язмаларын Хәрби округ газета, журналлары битләрендә даими бастырып килә. Табылганнарының исемнәрен туганнарына җиткерү өчен Татарстан һәм Башкортстан Республикаларының вакытлы матбугатына язмалар җибәреп тора. «Хәтер китабы»на да хәрби журналист юллап тапкан дистәдән артык сугышчының исеме кергән.

Татарстаннан читтә яшәсә дә, Р. Могыйнов туган ягы белән элемтәләрне өзми. Аның армиядә хезмәт итүче якташларыбыз турында язган очерклары, зарисовкалары, мәкаләләре, фотоинформацияләре даими рәвештә «Ленинчы» (Сарман), «Коммунизм таңы» (Минзәлә), «Октябрь юлы» (Балык Бистәсе), «Ильич юлы» (Биек Тау), «Ватан юлы» (Башкортстан, Авыргазы районы), «Авыл утлары» (Мөслим), «Татарстан яшьләре», «Ватаным Татарстан», «Комсомолец Татарии» газеталарында, «Сөембикә» («Азат хатын»), «Чаян» журналларында дөнья күреп торалар. Рафис Могыйнов шигырьләр, юморескалар, хикәяләр дә иҗат итә.

Шул еллардан соң,ул хәрби темадан читкә тайпыла алмый. Көчле кызыксынуы җәлеп итеп, үз эченә алып кереп китә. Хәрби хезмәттә кулыннан каләм төшерми язып, күп язмалар туплап, отставкага чыкканнан соң, гаиләсе белән туган якларына кайта.

1992 елда Рафис Могыйнов, армия хезмәтен тәмамлап, запаска чыга. Шул ук елны ул Чаллы шәһәренә кайта һәм «Шәһри Чаллы» газетасына баш мөхәррир урынбасары булып эшкә урнаша. Биредә, үзенең кабул итү бүлмәсендә, ул елларда Чаллыда гомер итүче Советлар Союзы Каһарманы Илдар Маннан улы Маннановның Сугышчан Дан музеен оештыра һәм аны Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре белән очрашулар, матбугат конференцияләре уздыру урынына әверелдерә.

Рафис Могыйнов иҗатның авыр юлын сайлаган. Татарстан егетләренең Бөек Ватан сугышы фронтларыннан язган хатларын табып алып, җыйнап, шуларны халыкка, киң катлам укучыларга җиткерү белән шөгыльләнә ул. Мондый гамәлләр журналистка җиңел генә бирелмидер. Күз алдына китерик, тоташ үлем утыннан торган сугыш кырларында Ватан өчен каннарын түккән фронтовикларның, фашист лагерьларенда җәфа чиккән совет солдатларының язмышын ачыклау, эзләнү, табышларның никадәр авыр, ачы булуы аның үзенә генә билгеледер.

Тора-бара, эзләнү-табышлар үз җимешләрен бирә. Тәҗрибәле журналистның әдәби һәм документаль-публицистик язмалары«Бөек Җиңү ачысы», «Тимер ташкынга каршы», «Сез ки газизләр... – Тоскуем по вас... », «Порохом пахнущие строки... – Хатларында дары исе...», – дип исемләнгән китапларында дөнья күрә. Әсәрләрендә урын аласы хатларның нинди телдә язылуын истә тотып, автор китапларын ике телдә, русча да, татарча да чыгару бәхетенә ирешә.

«Тимер ташкынга каршы» китабы белән Чаллы укучысы икеләтә горурлана, чөнки ул, башлыча, Республикабызның Советлар Союзы Герое, шәһәрдәшебез Илдар Маннановка багышланган документаль повестьне үз эченә алган. Повесть каһарман тупчының тормышын төрле яклап тасвирлап күрсәтә, шулай ук коралдашлары, сугыштан соңгы еллардагы эшчәнлеге турында да автор яңа мәгълүматлар бирә. Бу – каләм остасының гаять зур тырышлыгы, армый-талмый эзләнүләре нәтиҗәсендә туган әсәр.

Китапларда, Татарстаннан тыш, Оренбург һәм башка төбәк татарларының да хатлары урын алган. Шуңа күрә алар читтә яшәүче милләттәшләребез өчен дә бик кадерлеләр. Могыйнов шушы юнәлештә эшләүче бердәнбер язучы дисәм дә, ялгыш булмас.

Ул, гомере буе Бөек Ватан сугышында булган татарларның хатларын җыйнап, шуларны халыкка җиткерү теләге белән яши. Бу – бик кыйммәтле, бәһәсен аңлатып бетәрә алмаслык тарихи байлык! Шул кыйммәтләрне туплаган «Порохом пахнущие строки... – Хатларында дары исе...» дигән китабының исеменнән үк тетрәнеп куясың. Фашистларга карата нәфрәт хисләре белән язылган, канлы яу кырларыннан килгән хатларда, бернәрсә белән дә бутап булмый торган ис саклана. Кешелекне юк итәргә теләгән ул дары исен, уй белән дә әйләнеп карарга шүрләткән еллар, үткән гасыр агышы гына бетерерлек түгел шул. Хатлардан, сагыш, өйне сагынудан тыш, дошманны җиңеп кайтуга ышаныч аңкып тора. Алардан шундый юлларны укыйбыз:

*«...Исән булсак, Гитлерны юк иткәч кайтырбыз. Дошман турында газетта язылганнар бар да дөрес. Асу, ату, терелә́й күмү, тәнгә йолдыз ясау h.б. – болар бар да факт.*

*...Кичә полк командиры белән комиссардан хәрби заданиене яхшы үтәгән өчен благодарность алдым... Их! Бер сәгатькә генә кайтып килсәң иде. Шундый сагындым, белсәгез иде. Өйдән чыгып китүкәнгә дә бер ел тула.*

*...Үзебезнең тормыш элеккечә урман эчендә. Читен булса да түзәргә туры килә инде. Сугыш вакыты бит. Өстән бертуктаусыз «каргалар» очып торалар. Исән булсак, тиздән кайтырбыз. Хәзер фронтта эшләр көннән-көн алга бара. Дошманның берсен дә калдырмыйча бетереп киләбез. Андый ерткычлар, вәхшиләр дөньяда яшәргә тиеш түгелләр... ».*

Рафис Могыйновның сугыш каһарманнары истәлегенә багышланган әлеге

«Порохом пахнущие строки... – Хатларында дары исе...»дигән хезмәте бик тә үзенчәлекле. Ул – хатлар белән бергә, хат хуҗасы турында мәгълүматларны һәм туганнарының истәлекләрен дә үз эченә туплаган җыентык. Менә, мәсәлән, туганнарының әйтүе буенча, 1942 елның августында:

*«...Әгәр миңа тагын хат язарга туры килсә, язармын. Бик тә яшисем, туган якларга исән-сау әйләнеп кайтасым, сезне күрәсем килә... Күңел әлләни курыкмый да, шулай да фронтка якынлашабыз бит...»,* дигән юлларны язган хат авторының соңгы хаты икәнен искәртә.

Әдипнең бу китабы турында журналист Хәмит Мөхәммәтшин мондый сүзләр яза:

*«...сугыш кырларында һәлак булган сугышчылар рухына дога булып барсын. Ул һәркемне уяу булырга кисәтә. Һәм бу китап сугыш батырларына мәңгелек истәлек!».*

Хатлар. Хатлар... Алар бик күп. Аларның һәрберсендә сагыну, моң, кеше язмышлары ята. Шуларга өстәп, гаиләләр ятимлеге, илебезне чорнап алган фаҗига тасвирлана. Укучы бу хакта һәрдаим хәбәрдар булырга, онытырга тиеш түгел. Сугыш әле дә бетмәгән. Бу хакта безгә әле бүгенге көндә дә әледән-әле булып торган шартлаулар, ату тавышлары, бер гаепсезгә киселгән кеше гомерләре, искәртеп торалар.

Язучының китаплары китапханәгә йөрүчеләрдә зур кызыксыну уятты. Аларны кулына алган бер генә укучы да битараф кала алмый.

*«Бездә дә сугыш чоры хатлары саклана, киләчәктә аларны да яктыртып булмасмы?»* – дип мөрәҗәгать итүчеләр дә булды. Фронтовикларның саргаеп, таушалып беткән өчпочмаклы хатлары сугыш чорының әче дәлиле, кайтавазы, әби-бабайлар истәлеге, газиз туганнары хатирәсе булып, әле дә булса гаилә сандыкларында кадерләп саклана бит. Нинди генә булмасын, аларның кыйммәте зур, мәгънәләре тирәндә. Ул хатларда халык фаҗигасе, тормышы, язмышы, үткәне чагыла.

Запастагы Совет армиясе майоры Рафис Могыйнов Татар генераллары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары турында хатирәләр туплап, 2005 елда «Бөек Җиңү ачысы» китабын бастырып чыгарды.

Рафис Могыйновның хезмәтләрен югары бәяләп, хөкүмәтебез аны «Россия патриоты» медале белән бүләкләде. Ул –«Сугышчан хезмәтләре өчен» медаленең тулы кавалеры,Татарстан Республикасының Журналистлар берлеге әгъзасы (1974), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1999) иде.

Рафис Әмерсәяф улы 2013 елның 8нче июлендә каты авырудан вафат булды.